

Ләмберә районы Татар Тавласындагы фермер Азат Рәстәм улы Алмакаев эше турында еш язабыз. Ул алдынгы технологияләрдән файдалана, дәvләт ярдәм программаларында катнаша һәм икътисад-экономика вузын тәмамлаган буларак бизнес алып бара. Анын язмышында традиция һәм яналык шулкадәр органик рәвештә vрелеп бара, хәтта хормәт уята. Азат авыр хезмәт белән акча эшли, ләкин бу хезмәт затлы, татлы.
Сvзебез яна тор сыр житештерvче турында. «Качотта» дигән сырны Ви-кипедиядә итальянлыларнын ярым йомшак сыр дип билгеләнгән. Башлыча Үзәк Италиядә житештерелә. Һәм менә бу «Качотта» Татар Тавла авылы фермеры Азат Рәстәм улынын суыткычында тыныч кына олгерә. Азат Алмакаевнын базарга чыга торган чираттагы продукты булырга тиеш. Мона кадәр: пастеризацияләнгән сот, ряженка, каймак, эремчек булган. Һәм менә «Качотта» сыры белән эксперимент. Рәстәм улы Азатка ярты адым булса да, башкалардан алда булу ошый. Чираттагысы «Пармезан» булыр, ахры.
Искә тошерәм: Азат Рәстәм улы Алмакаев 2018 елда «Яна фермер» программасына керә. Бу вакытта әлеге программа буенча Мордовиянен авыл хужалыгы министрлыгы 5 елга миллион биргән. Ким дигәндә 10 сыер асрарга кирәк булган. Хәзер анын 17 баш сот котvе һәм яшь терлеге бар. Быел апрель аенда программада катнашуын туктата.
Рәстәм улы Азатнын бизнес-планы крестьян хезмәтен тогәл анлауга һәм vз куллары белән эшләv осталыгына нигезләнгән. Бизнесында vзе, гаиләсе, абые эшли һәм әние ярдәм итә. Оч-дvрт кеше. Кредитлар алмыйча, vз ресурслары хисабына vсеш алырга ярата Азат Алмакаев. Әйтеп китәргә кирәк, һәрбер эштә шикелле, бизнеста да торлесе була. Терлекләр санын арттыру белән сот сату мәсьәләсе кискен кvтәрелә. Чимал сотнен саклау һәм транспортлау буенча лимитлары бар, димәк, аны я перекупщикларга тапшырырга, я vз эшкәртvенне жайга салырга кирәк. Язма героебыз икенче юлдан китә: туган авылында тозелмәгән ангары булган. Үз вакытында автосервис белән шогыльләнергә теләгән. Үз коче белән ангарны сот цехы итеп vзгәрткән. Пастеризация очен һәм сотне аерым шешәләргә салу очен аппаратлар сатып алган һәм хәзер сотенен сыйфатын югалтмыйча бер атна саклап була. Азат Алмакаевнын сот продуктлары «Алтын коз-2021» кvргәзмәсендә комеш медаль яулаган. Бу инде танылу.
- Конемне фермадан башлыйм, - ди Азат Рәстәм улы. - Иртәнге савымнан сон сотне цехка алып барам. Коненә уртача 150-160 литр эшкәртәм. Кемнәрдер савым кvбрәк тә була, дияр. Ә минем очен продуктнын сыйфаты һәм табигый составы моһим. Сотебездә химик матдәләр юк, сыерларны табигый азык белән генә тукландырабыз: сыйфат очен жаваплы мин.
Халык та шуны раслый: соте бик яхшы сыйфатта.
Бизнесы алга атлый Азатнын. Пастеризатор артыннан фермер катык, каймак һәм

эремчек житештерv очен аппаратлар ала. Хәзер ул экологик чиста сот продуктларынын тулы линиясен тәкъдим итә ала. Алар арасында Татар Тавласынын «Качотта» дигән сыры да булачак.
Һәрбер эшнен vз унышлары һәм чишәсе мәсьәләләре бар - проблемалары. Әлбәттә, проблемалар булмый тормый. Мәсәлән, сот белән эшләv һәм яна продуктлар ясау очен грамоталы технолог кирәк, ди Азат Рәстәм улы. Хәзер ул белгеч хезмәтеннән файдалана, ләкин vзенен белгечен – технологын булдырырга ниятли. Шул чакта чималны тулысынча эшкәртvгә игътибар итәргә момкин булыр, икән. Фермер Азат Алмакаевнын бизнесы vсә икән, кадрлар, житештерv яки сату белән бәйле һәр проблема, әлбәттә, хәл ителәчәк.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**